


# Татарстан Республикасы Менделеев районы Бәзәкә авылы гербы

Авылыбызның гербы символлар һәм төсләр ярдәмендә аның тарихи, социаль-икътисади, мәдәни, географик үзенчәлекләрен күрсәтә.

Аның эчтәлеге. Дүртпочмаклы калкан эчендәге яшел җирлекнең үзәгендә милли бизәкле алтынсу чынаяктан (муллык, юмартлык, кунакчыллык символы) ике якка чыккан бодай башаклары бәйләме һәм нефть фонтаны җирле халыкның төп шөгыльләрен билгели. Композизициянең өске өлешен өч төстән торган лалә чәчәге төгәлли. Үзәктәге көмешсу-ак төс як-ягы алтынсу төс белән йөгертелгән кызыл төскә тоташа. Рухи яктан югары үсешкә ирешкән кеше (лалә), үзенең рәхимле (көмеш) булырга тиешлеген аңлап, тырышып хезмәт куя (кызыл төс) - җирне эшкәртә (яшел басу). Һәм Җир-ана аны хезмәте ( башак һәм нефть) өчен юмарт бүләкли. Нәтиҗәдә кеше муллыкка һәм яңарышка ирешә (лалә чәчәгенең кыр-кырлары йөгертелгән алтынсу төс). Гербның аскы өлешендәге җиңелчә дулкыннар белән бизәлгән зәңгәр тасма авылның географик урынын билгели (Кама елгасы буе).

Гербта Татарстан байрагы төсләре кулланыла. Яшел - табигать, уңдырышлылык, сәламәтлек, тормыш төсе. Кызыл - хезмәт, көч, матурлык, җитлегү, өлгергәнлек төсе. Көмеш (ак төс) – чисталык, затлылык, үзара аңлашу, алтын (сары төс) - житешлелек, зиннәтлелек, хөрмәт, фикерләү сәләтен билгели. Кара – яшәеш, зирәклек, гакыллылык төсе. Зәңгәр төс – намус, игелеклелек, рухи күтәрелеш төсе. Татар халкына хас төс һәм символлар ата-бабаларга хөрмәт, хәтернең тирәнлеген һәм даими саклануын аңлата.

*Тәрҗемә авторлары: Башарова Ф.З., Мәхмутова А.Х.. Май,2018ел.*